МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Пушкина, д. 66/33, г. Казань, 420015

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ

Пушкин ур., 66/33нче йорт, Казан ш., 420015

Тел.: (843) 264-74-01, факс: (843) 292-07-26. mkrt@tatar.ru, mincult.tatarstan.ru

**ПРИКАЗ** г.Казань **БОЕРЫК**

**14.03.2017** **№ 233 од**

Казан шәһәре, Нагорная урамы,
39 нчы а йорт адресы буенча урнашкан
“Торак йорт, XIX гасыр ахыры”
төбәк әһәмиятенә ия мәдәни мирас
объекты территориясе чикләрен
раслау турында

“Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) турында”гы 2002 елның 25 июнендә кабул ителгән 73-ФЗ номерлы законына, “Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында”гы 2005 елның 1 апрелендә кабул ителгән 60-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, махсус җайга салына торган шәһәр төзелеше эшчәнлеге объектлары буларак, федераль әһәмияткә ия мәдәни мирас объектларын һәм аларның территорияләрен саклауны һәм дәүләт тарафыннан саклап тотуны тәэмин итү максатларында,

**БОЕРАМ:**

1. ТАССР Министрлар Советының 1990 елның 2 августында кабул ителгән “Казан шәһәре һәм республика районнары архитектура корылмаларын җирле әһәмияткә ия архитектура һәйкәлләре исемлегенә кертү турында”гы 290 нчы карары нигезендә, дәүләт сагына куелган Казан шәһәре, Нагорная урамы, 39 нчы а йорт адресы буенча урнашкан “Торак йорт, XIX гасыр ахыры” төбәк әһәмиятенә ия мәдәни мирас объекты территориясе чикләрен расларга (1 нче кушымта).
2. Казан шәһәре, Нагорная урамы, 39 нчы а йорт адресы буенча урнашкан “Торак йорт, XIX гасыр ахыры” төбәк әһәмиятенә ия мәдәни мирас объекты территориясен файдалану режимын расларга (2нче кушымта).
3. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.


Министр А.М.Сибагатуллин

_____ел_____боерыкка

1 нче кушымта

Казан шәһәре, Нагорная урамы, 39нчы а йорт адресы буенча урнашкан “Торак йорт, XIX гасыр ахыры” төбәк әһәмиятенә ия мәдәни мирас объекты территориясе ЧИКЛӘРЕ

Казан шәһәре, Нагорная урамы, 39 нчы а йорт адресы буенча урнашкан “Торак йорт, XIX гасыр ахыры” төбәк әһәмиятенә ия мәдәни мирас объекты территориясе чикләре картасы (схемасы)



Казан шәһәре, Нагорная урамы, 39 нчы а йорт адресы буенча урнашкан “Торак йорт, XIX гасыр ахыры” төбәк әһәмиятенә ия мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең **картографик тасвирламасы**

Казан шәһәре, Нагорная урамы, 39 нчы а йорт адресы буенча урнашкан “Торак йорт, XIX гасыр ахыры” төбәк әһәмиятенә ия мәдәни мирас объекты территориясе чикләре түбәндәгечә үтә:

**Төньяк-көнчыгыш өлеш**: Койма буйлап (н.3-4).

**Көньяк-көнчыгыш өлеш**: Койма буйлап (н.4-5), бина буйлап (н.5-6).

**Көньяк-көнбатыш өлеш**: Мәдәни мирас объектының көньяк фасады буйлап (н.6-1).

**Төньяк-көнбатыш өлеш**: койма буйлап (н.1-3).

Казан шәһәре, Нагорная урамы, 39 нчы а йорт адресы буенча урнашкан “Торак йорт, XIX гасыр ахыры” төбәк әһәмиятенә ия мәдәни мирас объекты территориясенең **борылыш нокталары таблицасы**

| № точки | Координаты точки в МСК 16 | | Координаты точки во всемирной геодезической системе координат 1984 года (WGS 84) | |
|---|---|---|---|---|
| | X | Y | Широта, B | Долгота, L |
| 1 | 477145.10 | 1305433.20 | 55°48'5,57"N | 49°07'6,35"E |
| 2 | 477171.70 | 1305436.73 | 55°48'6,43"N | 49°07' 6,56"E |
| 3 | 477168.52 | 1305465.96 | 55°48'6,32"N | 49°07' 8,23"E |
| 4 | 477158.71 | 1305464.62 | 55°48'6,00"N | 49°07' 8,16"E |
| 5 | 477157.92 | 1305477.35 | 55°48'5,98"N | 49°07' 8,89"E |
| 6 | 477148.57 | 1305476.54 | 55°48'6,78"N | 49°07' 8,84"E |
| 7 | 477149.20 | 1305464.13 | 55°48'5,70"N | 49°07' 8,13"E |
| 8 | 477144.02 | 1305463.51 | 55°48'5,53"N | 49°07' 8,09"E |
| 9 | 477144.41 | 1305459.75 | 55°48'5,54"N | 49°07' 7,87"E |
| 10 | 477142.37 | 1305459.59 | 55°48'5,48"N | 49°07' 7,87"E |
| 11 | 477143.59 | 1305446.49 | 55°48'5,52"N | 49°07' 7,11"E |
| 12 | 477139.14 | 1305445.95 | 55°48'5,37"N | 49°07' 7,08"E |
| 13 | 477139.84 | 1305438.54 | 55°48'5,39"N | 49°07' 6,66"E |
| 14 | 477144.46 | 1305439.04 | 55°48'5,54"N | 49°07' 6,69"E |

Казан шәһәре, Нагорная урамы, 39 нчы а йорт адресы буенча урнашкан “Торак йорт, XIX гасыр ахыры” төбәк әһәмиятенә ия мәдәни мирас объекты территориясен **файдалану режимы**

Төбәк әһәмиятенә ия мәдәни мирас объекты территориясе чикләрендә түбәндәгеләр рөхсәт ителә:

мәдәни мирас объектының физик яктан саклануын тәэмин итүгә юнәтелгән саклау эшләрен башкару, шул исәптән, консервацияләү, ремонтлау, реставрацияләү һәм заманча файдалануга яраклаштыру;

мәдәни мирас объектларының бөтенлегенә зыян салмаган һәм мәдәни мирас объектының бүгенге шартларда кулланылуын тәэмин итү мөмкинлеге биргән хуҗалык эшчәнлеге алып бару;

түбәндә рөхсәт ителгән файдалану төрләре нигезендә, булган капиталь төзелеш объектлары исемлеге тәкъдим ителә, шулай ук җир кишәрлекләреннән файдалану (капиталь төзелеш объектлары төземичә һәм капиталь булмаган корылмалар урнаштырмыйча):

- мәдәни үсеш объектлары (код 3.6);

булган сызымнар, үлчәүләр һәм тарихи тиңдәшләр буенча мәдәни мирасның юкка чыккан элементларын һәм өлешләрен торгызу;

мәдәни мирас объектының бөтенлеген боза торган вакытлы корылмалар һәм объектларны сүтү;

булган инженер инфраструктурасы объектларын капиталь ремонтлау (тышкы су белән тәэмин итү челтәре, канализацияләр, җылылык, газ, электр белән тәэмин итү, телефонлаштыру);

мәдәни мирас объектын саклап калу, файдалану һәм популярлаштыруга юнәлдерелгән территорияне төзекләндерү:

- мәйданчыкларга, якын килү һәм транспорт уза торган урыннарына традицион материаллар (таш, гранит һәм табигый материалга охшаш башка материаллар) түшәү;
- тарихи мохит элементлары характеристикаларына җавап бирә торган аерым урнаштырылган яктырту җайланмаларыннан файдалану;
- агачларның кыйммәтле төрләрен саклап калу;

мәдәни мирас объекты фасадында биеклеге 2,0 метрдан артмаган мәгълүмати язулар һәм билгеләмәләрне мәдәни мирас объектының 2 нче катындагы тәрәзә уемнарының өске чигеннән югарырак күтәрмичә урнаштыру;

кулланучылар игътибарына мәгълүмат җиткерү өчен оешмаларның элмә такталарын, тышкы мәгълүмат чараларын биеклеге 2,0 метрдан артмаслык һәм мәдәни мирас объектының 2 нче каты тәрәзә уемнары билгесеннән өстәрәк булмаслык итеп урнаштыру;

эшләр археологлар тарафыннан күзәтелгән очракта территорияләрнең директив тигезлеген киметү, ишегалды территорияләрен вертикаль планлаштыру.

Югарыда атап үтелгән эшләр Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тарафыннан килештерелгән мәдәни мирас объектларын саклап калу буенча проект документларын әзерләү һәм эшләр башкару буенча йөкләмәләр, күрсәтелгән эшләрнең башкарылуын Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы контрольдә тоткан очракта – проект документлары, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тарафыннан мәдәни мирас объектын саклау эшләре үткәрергә язмача рөхсәт кәгазе нигезендә башкарыла.

Җирле (муниципаль) әһәмияткә ия мәдәни мирас объектлары территориясе чикләрендә түбәндәге эшләр **тыела**:

- мәдәни мирас объектын яки аның аерым элементларын, мәдәни мирас объектының тарихи-шәһәр төзелеше тирәлеген саклау белән бәйле булмаган җир казу, төзелеш, мелиоратив һәм башка эшләр башкару;

- капиталь төзелеш объектларын төзү һәм һәйкәл территориясендә булган капиталь төзелеш объектларының күләм-киңлек характеристикаларын арттыру;
- мәдәни мирас объекты фасадына һәм түбәсенә кондиционерлар, зур габаритлы антенналар һәм инженерлык җиһазларының башка элементларын кую;
- тышкы реклама чараларын урнаштыру;
- җир өстеннән инженерлык инфраструктурасы объектларын (тышкы сууткәргеч челтәрен, канализация, җылылык, газ һәм электр белән тәэмин итү, телефонлаштыру) үткәрү;
- киосклар, павильоннар, өслекләр, кече архитектура формалары кую, юкка чыкканнарын торгызу искәрмә булып тора;
- мәдәни мирас объекты һәм аның янәшәсендәге корылмаларга динамик йөкләнеш тудыручы технологияләрдән файдалану;

- мәдәни мирас объекты территориясен теләсә кайсы төрдәге һәм формадагы көнкүреш калдыклары белән чүпләү;
- машина кую урыннарын көйләү.